**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2025 елның «23» сентябреннән № 1-1

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясындагы 6 өлеше, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 53 статьясындагы 2 пункты, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Тарнавский Егор Александрович шәхси гаризасы нигезендә,Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Яңа Чишмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге депутаты итеп сайлануына бәйле рәвештә Тарнавский Егор Александровичның Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасыннан үз теләге белән отставкага китүен шәхси гаризасы нигезендә кабул итәргә.
2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Тарнавский Егор Александрович вәкаләтләрен 2025 елның 22 сентябреннән вакытыннан алда туктатылган дип санарга.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советының
беренче утырышында рәислек итүче
Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль
районы Советының Шахмай авыл җирлегеннән депутаты Г.М. Сөләйманов